# Мәктәп хәбәрчесе

**№6**
**(№9)**
**август 2019 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru






**/Мөхәррир сүзе /**

***Якынлашып килүче БЕЛЕМ БӘЙРӘМЕ белән!***

1 сентябрь – Белем бәйрәме. Инде күп гасырлар дәвамында нәкъ менә бу көнне укучылар иртән-иртүк мәктәпкә ашыгалар. Аларны инде алардан да иртәрәк мәктәпкә килгән укытучылар каршы алалар. Яңа уку елы башлана... Бу көнне укытучы да, укучы да Яңа ел кебек кабул итәдер. Күңелдә яңа өметләр, яхшырак укырга теләк, күбрәк белем алырга омтылыш тоела. Укытучы күңелендә яңача дәрес төрләре, мавыктыргыч эшләр, укучысына карата җылы мөнәсәбәт тә сизелә. 1 сентябрь иртәсе белән мәктәп йорты кабаттан шатлыклы авазларга күмеләчәк. Ул көн чәчәк бәйрәме дә. Һәр укучы яраткан укытучысын Белем бәйрәме белән котларга әзерләнә.

Сентябрь – авыл хезмәтчәннәренең урып-җыю вакыты булса, бу айдан мәктәптә белем орлыкларын чәчү башлана. Тыз-быз мәктәп тормышы шушы көннән һәр укучы йөрәгенә юл табып, белем өләшергә, ягъни чәчәргә тотына. Икмәк үстерү игенче белән һава торышына бәйле булса, мәктәп уңышы укучы белән укытучы тырышлыгына бәйле, әти-әниләребезнең ярдәменә дә карый. Шуңа күрә, Белем көне – укытучылар белән укучылар бәйрәме генә түгел. Белем көне әти-әниләр өчен дә, студентлар өчен дә, аң-белемнәрнең дөньяда иң зур байлык икәнен аңлаган кешеләр өчен дә зур бәйрәм!

Укучым. Дөньяда барлык нәрсәнең чиге бар, белем алуның, акыл туплауның гына чиге юк. Шуңа күрә Белем көнен шатланып кабул итүегезне телим.

Әлеге бәйрәм белән барлык укучыларыбызны, укытучыларыбызны, әти-әниләрне чын күңелдән котлыйбыз! Укыту-укуда уңышларга ирешегез, алган белемнәр бары шатлык алып килсен һәм файда китерсен!

***Фәнүзә Гафиятуллина. Мөхәррир, ана теле һәм әдәбияты укытучысы***

## *30 август Туган көнең белән Ватаным, Республикам минем ТАТАРСТАН!*




Кадерле укучылар, укытучылар, әти-әниләр.

Сезне ихлас күңелдән **Республика көне** белән котлыйбыз. Бу бәйрәм күпмилләтле Татарстаныбыз халкының берлеген, дуслыгын, бердәмлеген гәүдәләндерә. Республикабызның үсеш нигезе, уңышлары һәм чәчәк атуы нәкъ менә шуңа бәйле. Бер-беребезне аңлап һәм үзара ярдәмләшеп яшәгәнгә, без хыялларны тормышка ашыра һәм югары нәтиҗәләргә ирешә алырбыз.

Укучылар! **Илебез һәм милләтебезнең киләчәге Сезнең кулларда.** Ватаныбызга карата булган яратуыгыз, һичшиксез, аны тагын да күркәм итәчәк. Сезне тагын бер кат бәйрәм белән.

**“Мәктәп хәбәрчесе” редколлегиясе**

## *Ак юллар сезгә, дуслар!*

Әле кайчан гына мәктәп йорты “Соңгы кыңгырау” бәйрәме белән үзенең янә бер чыгарылышын олы тормыш юлына озаткан иде. Бердәм дәүләт имтиханнарын тапшырып, мәктәпне тәмамлаган укучыларыбыз төрле уку йортларына таралдылар. Галимова Нәзилә белән Хөснуллина Алия Казан дизайн техникасы колледжында һөнәри белем алачаклар. Магизов Ильфир КДАХАның икътисад, Сафиуллин Илсур КНИТУның социотехник системалар факультетларында укуларын дәвам итәчәк. Мөхәммәтҗанов Айрат Ульян шәһәрендәге медицина университетына укырга керде. IX сыйныфны тәмамлап киткән Сәгъдиева Таңсылу Яр Чаллы шәһәренең технология техникумында һөнәр үзләштерәчәк.



Мәктәпне тәмамлап киткән абый-апаларына алмашка яңа уку елында беренче сыйныфка дүрт яшь егетебез киләчәк. Болар – бакча төркемен тәмамлаган Замалетдинов Зөлфәт, Сәгъдиев Рәмзис, Хәбибрахманов Абдулла белән, авылга быел гына кайткан дуслары – Донсков Артур. 29 август көнне аларны котлап, РУЭС оешмасы тарафыннан “Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит” акциясе буенча уку әсбаплары тапшырылды.




## *Лагерь күңелле үтте*

Менә, ниһаять, кояшлы, җиләкле җәй килде. Бик үк җиңел булмаган, җаваплы уку елын тәмамлап, мәкәпнең "Дуслык" ял лагерена җыелдык. Отрядларның исемнәре генә дә ни бит әле – **"Кояшкай"** һәм **"Елмай"**.

Лагерь ачылу тантанасыннан соң, бирeдә чын-чынлап яңа мавыктыргыч тормыш башланды. Иртәнге гимнастика, берсеннән-берсе тәмле ашлар, төрле-төрле ярышлар – барысы да шәп иде. "Күңелле стартлар", "Бәхетле очрак", табигатьтәге чаралар безгә бик ошады. "Янгын куркынычсызлыгы көне"ндә очрашуга килгән Фоат абыйның авызыннан чыккан һәр сүзен тыңлап, күңелебезгә салып бардык. "Хуҗалар тавы"на оештырылган экскурсия дә күңелгә кереп калды.

Көнебезнең бер минуты да бушка үтмәде. Рәхәтләнеп футбол уйнадык, төрле мавыктыргыч мультфильмнар, кинолар карадык. Төрле мастер-классларда катнаштык. Лагерьның соңгы көне килеп җиткәнне сизми дә калдык. Шул арада Казан шәһәренә "Әкият" кә "Йолдыз тапкан кыз" дип аталган курчак театрына бардык. Безнең күңелле ялыбыз өчен бик күп көч куйган җитәкчебез Алсу апа, тәрбиячеләр Зөлфия һәм Рузилә апаларга зур рәхмәтебезне җиткереп калабыз. Тәмле ашлары белән сыйлаган пешекче апаларыбызга да олы рәхмәтебезне белдерәбез.
Озакламый Биләргә "Сәләт" лагерена да бару бәхетенә ирештек. Без "Күлтәгин", "Кодрак хан", "Атилла" аланнарында булдык. Тагын яңа дуслар таптык, кичке чараларда уйнадык. Көненә икешәр мастер-классларда катнашып, яңа шөгыльләр үзләштердек. Отряд әйдаманнарыбыз да безгә карата җылы мөнәсәбәттә иде.

Тулаем алганда, җәйге лагерьлар күңелле үтте.

***VI сыйныф укучысы Самат Гафиятуллин***

## *Җәйге айлар – хезмәт чоры*

Җәй – һәркемнең көтеп алган җылы, рәхәт ел фасылы ул. Һәркем бу вакытның тәмен тоеп калырга, укудан бераз ял итәргә, яңа дуслар табарга тырыша. Минем җәйге ялым һәр елны да бертөрлерәк уза. Хәлдән килгәнчә гаиләмә йорт эшләрендә булыштым. Күп вакытым күмәк хуҗалыкта көтү көтеп узды. Урып-җыю башлангач әти абыем белән икебезне ындыр табагына күчерде. Бу эштә мин генә түгел, Халид һәм Муса Нурматовлар, апам Гүзәл, Галимов Рияз да эшләде. Икмәкнең өстәлебезгә җиңел генә килмәгәнен аңлау, кадерен күбрәк белер өчен файдалы хезмәт бу. Икенчедән, кесәңдә үзең эшләп тапкан акчаң булуы рәхәт!

Иртәдән кичкә кадәр эшләү бик арыта, әлбәттә. Шулай булса да зарланмыйм. Хезмәт белән чыныгып үсү һәркем өчен дә кирәк.

***VIII сыйныф укучысы Илдус Камалов***


## *Казаннарга барган идем...*



Мин җәйге каникул көннәрендә апаларга кунакка Казанга бардым. Республикамның башкаласы соңгы елларда үзгәрә, матурлана бара. Тарихи истәлекләргә бай башкалабызның әллә нинди матур җирләре бар икән. Урамнары мең төрле төстәге чәчәкләргә күмелеп утыра. Һәркайда Татарстан символларын да, "Worldskills"ка әзерлек чараларын да күрергә мөмкин. Халкымның бердәмлегенә, уңганлыгына ишарә ясаган бу матурлыклар Казанга килүчеләрдә илемә карата, һичшиксез, матур тәэсирләр барлыкка китерә. Чөнки һәркайда сәнгать - милли бизәкләр югары дәрәҗәдә итеп эшләнгән.

Туганнарым мине Кабан күле, Кремль буйларында, "Әкият"курчак театры бинасында, башка бик күп урыннарда йөрттеләр. Кая гына барсам да, һәрбер урын үзенчәлекле ягы белән аерылып тора. Берсен-берсе кабатламый торган төзелешләр монда иң көчле архитекторлар эшләгәнен күрсәтә. Мин шундый күп милләтле халыкны үзенә сыйдырган илем белән горурланып кайттым. Шуңа да югары уку йортларына Җир шарының теләсә кайсы почмагыннан белем алырга килгәннәренең сәбәбенә төшендем. Матурлык кына түгел, халкымның зыялылары биргән белем дәрәҗәсе дә, димәк, меңнәрчә чакырымнарга таралган. Үз туган җиремә, үз анам теленә, гореф – гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләгән әти-әниемә, мәктәбемә, минем туган ягымнан да матур, иркен ил юк икәнлеген күрсәткән апаларыма рәхмәт.

***VIII сыйныф укучысы Әминә Туктамышева/***



## *Ямьле Чирмешән буйлары*

Купләребезнең җәйге каникул көннәре Чирмешән елгасында су коенып һәм балык тотып үтә. Бормаланып аккан елга авылыбызга кабатланмас ямь өсти. Гомумән алганда, Чирмешәнсез Майнаны күз алдына китерү дә мөмкин түгел. Елганың хәзерге торышы үткәндәге хәленнән күпмегә аерыла икән – бу мәкаләдә шуңа ачыклык кертергә булдык.

Тарих дәвамында Түбән Майна халкының яшәеше Чирмешән елгасына бәйле булган. Әби-бабаларыбыз гомер-гомергә Чирмешәннең суларын файдаланып, балыгын тотып, агым көче белән тегермән эшләтеп яшәгәннәр. Авылыбызның борынгы исемнәренең берсе “Чирмешән” булган. XVIII гасыр ахырына караган безнең авылның икътисади тасвирламасында Чирмешән елгасына шундый бәяләмә бирелә: *“Малый Черемшан в жаркое летнее время бывает глубиною в два аршина, шириною в 15 сажень. В ней рыба щуки, окуни, плотва, ерши, пескари, караси. Вода по употреблению здорова.”*

Елганың ул замандагы хәле белән хәзерге торышын чагыштырсак, шактый зур үзгәрешләр барлыгын күрербез. Балык төрләре элеккечә калсалар да, суы күптән инде эчәр өчен кулланылмый. Чирмешәннең тирәнлеге һәм киңлеген элеккеге замандагы белән чагыштырганда дүрт тапкырга кимрәк. Авылның 1854 елгы планда ярга якын урнашкан түбәнлекләрнең елганың култыклары хәлендә торганлыгы күренә (өстәге рәсем).

Чирмешәннең саегуы аның тирәсендәге урман һәм куаклыкларны кисеп бетерүгә бәйле. Чистай өязенең XVIII гасыр ахырында сызылган атласында Кече Чирмешәннең Чуаш Ялтаны турысыннан алып Гәрлинкә астына кадәрге буенда тоташтан куаклык эченнән акканлыгы күренә. Елганың Ялтаннан югарыгы агымында ярлар ачык булсалар да, күп санлы урман инешләре яздан кышка кадәр агып, Чирмешәнне туендырып торганнар. Шунысы игътибарга лаек, Чирмешән Кыдырата авылларыннан алып Тирмән алдына кадәрге өлешендә якын тирәдәге башка җирләрдәгедән киңрәк булуы белән аерылып тора. Моңа әлеге арада елганың элек-электән буылуы нәтиҗәсендә ярларның ашалуы сәбәп булып тора. Борынгы заманнардан алып сугышка кадәрге чорда Чирмешән су тегермәнен, ә сугыштан соңгы елларда электр станциясен эшләтү өчен буылган. Электр станциясе эшләүдән туктаганнан соң буалар махсус су тирәнәйтү максатыннан гына буыла. Язгы ташулар һәм көчле яңгырлар вакытында әлеге буалар ерылалар һәм аларны ел саен яңартырга туры килә. Шуңа күрә киләчәктә су ташуларга бирешми торган тотрыклы буа төзү авыл өчен иң әһәмиятле эшләрнең берсе булып тора.



Чирмешән суының кимүе соңгы елларда көчле су басулар булмаудан да күренә. Бөтен тугайларны су баскан соңгы язгы ташу 2011 елда булган иде. 1979 елгы ташу вакытында авылның югары очлары су астында кала. Аеруча көчле су басу 1897 елда була. Ул елны язгы ташу вакытында авыл биш утрау хәлендә кала. Урамнар шаулап аккан елгаларны хәтерләтә һәм көчле су агымы бураларга кадәр агызып китә.

Чирмешәндә боз китү элек-электән халык көтеп ала торган вакыйгалардан саналган. Авылның яше-карты, күңелле тамаша күрергә килгәндәй, боз китүен карарга су буйларына җыелган. Бозлар китмичә калуны халык авыр ел килүгә юраган. Яшьләр һәм бала-чагалар боз өстенә учаклар ягып җибәргәннәр, яр буенда төрле уеннар уйнаганнар. Кызганычка каршы, мондый гореф-гадәтләр соңгы елларда инде онытылып бара.

“Чирмешән” атамасының бик борынгы булуы төрле тарихи чыганаклар белән раслана. 922 елда Болгар иленә килгән Әхмәт ибне Фадлан язмаларында Олы Чирмешән - “Җәрамсан”, Кече Чирмешән – “Җаушир” исемнәре белән аталган. Лаврентий елъязмасында 1183 елда Биләр шәһәренә сугыш белән килгән урыс гаскәренең “Черемисан” елгасын үтүе турында хәбәр ителә. “Чирмешән” атамасын йөрткән елга һәм авылларны Рәсәйнең төрле төбәкләрендә очратырга мөмкин икән. Татарстанның Апас районында, Башкортстанда, Пермь якларында, Алтайда Чирмешән елгалары, Чиләбе өлкәсе һәм Приморск краенда Чирмешән исемендәге бистәләр барлыгы билгеле.

Фәндә “Чирмешән” сүзенең килеп чыгышы һәм мәгънәсе турында төгәл генә аңлатмалар юк. Бу атаманың тамырында борынгы төрки телдә гаскәр дигәнне аңлаткан “чирү” сүзе тора булса кирәк. Түбән Майнаның гади халык сөйләмендә “чирмешән” сүзе кайвакыт “елга” мәгънәсендә кулланыла. Мәсәлән: *“Аларның чирмешәннәре бик сай икән..”, “...ул авылда чирмешән юк, күл генә бар”* дигән сүзләрне ишетергә туры килгәли.



## Ике гает

**/Бәйрәмнәребез /**

Ураза гаете – Ислам динендәге иң олы ике бәйрәмнең берсе. Бу бәйрәм туганнарың, дусларың белән бергә очрашырга, якынаерга мөмкинлекләр тудыра. Аеруча балалар өчен. Шуңа күрә без, укучылар, 4нче июнь көнендә мәктәп янына җыелдык. Директор Насыйров Рафик абый бәйрәм белән котлап чыгыш ясады. Аннан соң һәр бала өчен иң көтелгән вакыт житте: Рафик абый мәчеттән бирелгән бүләкләрне өләште. Ләкин шуның белән бәйрәм вакыйгалары тәмамланмады: без табигать кочагында ял итү өчен экскурсиягә киттек. Болгар куаклыгы – туган ягыбызның иң матур җирләренең берсе. Шул матурлык кочагында бик күңелле ял иттек. Балалар төрле уеннар уйнадылар. Ә малайлар Чирмешәннең текә ярына менү буенча ярыштылар. Уйнап арып талганнан соң бик тәмле итеп пешкән уха белән сыйландык. Көнне матур гына уздыргач, күтәренке кәеф белән өйләребезгә таралыштык.



11нче август көнне безнең мәктәптә Корбан гаете бәйрәм ителде. Тәмле куллы оста пешекче апалар балаларны гает коймаклары белән сыйладылар. Гадәттәгечә, Рафик абый Гает хөрмәтенә безнең мәктәптәге һәр балага бүләкләр өләште. Шуннан соң Казаннан килгән кунаклар тарафыннан мавыктыргыч һәм файдалы мастер-класслар үткәрелде. Илсөяр апа 8-11 сыйныф кызлары белән стринг-арт техникасын кулланып, кадак һәм җепләр ярдәмендә матур картиналар ясадылар. Ә түбәнрәк сыйныф кызлары тәлинкәләрне матур бизәкләр белән бизәделәр. Башлангыч сыйныфлар өчен Илсөяр апаның кызы Мәрьям слайм ясау серләрен ачты. Малайлар Рома абый белән остаханәдә киштә ясарга өйрәнделәр. Шундый файдалы һәм күңелле үтте безнең Корбан гаете.

***Бәйрәм чараларыннан репортажны Нәзирә Әхмәтова һәм Сара Насыйрова әзерләде***

## / Безнең спорт /

Җәйге спорт уеннары, әлбәттә инде, милли бәйрәм – “Сабан Туе” белән бәйле. Безнең мәктәп укучылары да бу бәйрәмдә бик актив катнаштылар. 8 июнь көнне узган авыл “Сабан Туе” көрәшендә кече яшьтәгеләр арасында Галимов Рияз, урта яшьтәгеләр арасында Камалов Илдус батыр калдылар.

9 июньдә Аксубай “Сабан Туенда” көрәштә үз авырлыкларында Камалов Илдус беренче, Хәбибрахманов Ильяс икенче урыннарны алдылар.

16 июньдә Мәләкәс (Димитровоград) шәһәрендә узган “Сабан Туенда” көрәшеп, Камалов Илдус белән Хәбибрахманов Ильяс үз авырлыкларында беренче урынга чыктылар.

29 июнь көнне 3нче сыйныф укучысы, Гафиятуллин Фаил, Аксубайда яшьләр көненә багышлап уздырылган шахмат турнирында 3нче урынны яулап кайтты.




## / Котлыйбыз! /




Ямьле җәйдә туган көннәрен билгеләп үтүче бакча балалары Сафиуллина Гөлсемне (9 июль), Җамалетдинов Фирдүсне (2 июль), бәйрәмнәре белән котлыйбыз.

Мәктәп укучыларыннан Җамалетдинов Зөлфәтне (23 июль), Насыйрова Кәүсәрне (18 август), Гафиятуллин Фаилне (24 июнь), Нурматова Зәйнәпне (29 июль), Залиев Салаватны (6 август), Нурматов Мусаны (6 июль), Хөснуллин Маратны (25 июнь), Залиева Илдеярне (24 июль), Галиуллина Айсылуны (28 июль), Камалова Гүзәлне (21 июль), Фәйзуллина Зөлфинәне (1 август) туган көннәре белән ихластан котлыйбыз. Сәламәтлекнең ныгын, укуда уңышлар, хыялларының тормышка ашуларын телибез.

Кадерле хезмәткәрләреннән Насыйрова Гөлүсә (24 июнь), Гафиятуллина Руфия (26 июнь), Сафиуллина Алсу (16 июль), Садыйкова Галия (20 июль), Сабитова Илсөяр (8 август) апаларны, Шакиров Азат абыйны (19 июнь) гомер бәйрәмнәре белән чын күңелдән котлыйбыз. Сәламәтлекле озын гомер, гаилә бәхете, эшләрендә уңышлар телибез.

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:**
Әминә Туктамышева, Алия Гыйззәтуллина
Виктория Нукина, Нәзирә Әхмәтова
Зөлфирә Сафиуллина, Рузилә Мөхәммәтова
Сара Насыйрова